ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.06.2026 ел Баулы шәһәре №75

Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча төбәк ведомствоара комиссиясе турында» 2023 елның 30 мартындагы 790-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы (1 нче кушымта);

- Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 июнендәге
75 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

1 нче кушымта

| | | |
|---|---|---|
| Бакиров Д.Л. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Хөснуллина И.И. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Хисамиева Г.Р. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының эш оештыру бүлеге начальнигы, комиссия секретаре; |
| Адамова Р.А. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы; |
| Гайсин А.С. | - | «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Гарифуллина Л.Р. | - | Баулы инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча); |
| Каһиров Р.А. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек начальнигы; |
| Козикова Л.В. | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгүльлек һәм социаль яклау министрлыгының Баулы районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Лендяева М.И. | - | «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалының Баулы муниципаль районындагы вәкиллегенең социаль координаторы (килешү буенча); |
| Лыкова О.Н. | - | Баулы сукырлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча); |
| Мингалиева Э.С. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары; |
| Михайлова А.А. | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе; |
| Моратова Р.А. | - | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» МКУ җитәкчесе; |

| | | |
|---|---|---|
| Самонйна О.А. | - | «Баулы шәһәре һәм Баулы районы идарәче компаниясе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Таҗетдинов Д.И. | - | “Безнең ишегалды” торак милекчеләре ширкәте рәисе (килешү буенча); |
| Хәбиров Э.Ф. | - | Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы; |
| Хәлитов И.Н. | - | Баулы шәһәре, Баулы һәм Ютазы районының хәрби комиссары (килешү буенча); |
| Хафизов И.И. | - | «Барысы өчен дә ачык дөнья» Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең иректле сертификация системасы эксперты (килешү буенча); |
| Шәяхмедова А.Р. | - | «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалы вәкиле - инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килешү буенча); |
| | - | Баулы муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары (ихтыяҗ буенча, килешү буенча). |

---

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 10 июнендәге
75 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

2 нче кушымта

Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиянең вәкаләтләрен һәм эшчәнлеген оештыру тәртибен билгели (алга таба – комиссия).

1.2. Комиссия Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм итү мәсьәләләре буенча эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр арасында килешенгән гамәлләрне тәэмин итү өчен төзелгән координация органы булып тора.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив-хокукый актларына, муниципаль норматив-хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә нигезләнә.

1.4. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Баулы муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү эшчәнлеген оештыру белән бәйле мәсьәләләрне карау;

- Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) катнашучыларның гаилә әгъзаларының (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары), шул исәптән аларга социаль ярдәм, медицина һәм психологик ярдәм чаралары күрсәтелгәндә, алар өчен реабилитация, озак вакытка өйдә карау оештырылганда, эшкә урнашуда, белем алуда ярдәм иткәндә махсус хәрби операциядә катнашучыларны адреслы озата баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләү;

- Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләренә мониторинг ясау, мөрәҗәгатьләрне караганда Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- гражданнарны патриотик тәрбияләү өлкәсендә агарту эшчәнлеген оештыруга бәйле чаралар әзерләү;

- махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын адреслы озата бару һәм аларга ярдәм чаралары күрсәтү мәсьәләләрен хәл иткәндә Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының, аның карамагындагы оешмаларның, башка оешмаларның ведомствоара хезмәттәшлеген оештыру;

## 2. Комиссиянең хокуклары

Комиссия хокуклы:

- комиссия утырышларына Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре вәкилләрен, шулай ук Баулы муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен чакырырга;
- Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләреннән, Баулы муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча кирәкле материаллар соратып алырга;
- махсус хәрби операциядә катнашучыларга аларның гаилә әгъзаларына ярдәм һәм башка төр ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләр буенча Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актлары проектларын эшләүдә катнашырга;
- комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча белгечләр һәм экспертлар җәлеп итәргә;
- комиссия карарлары проектларын һәм тәкъдимнәрне эшләү, материалларны оператив һәм сыйфатлы әзерләү өчен эш төркемнәре төзергә, әлеге төркемнәрнең эш тәртибен билгеләргә.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру

3.1. Комиссия составы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Баулы муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләреннән төзелә.

3.2. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары керә.

3.3. Комиссия рәисе комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, аның эшен координацияли һәм оештыра. Комиссия рәисе булмаган чорда аның вәкаләтләрен комиссия рәисе урынбасары башкара.

3.4. Комиссия рәисе урынбасары комиссия кабул иткән карарларның әзерләнүен һәм үтәлешен тикшереп тора.

3.5. Комиссия секретаре:

- комиссиянең чираттагы утырышы көн тәртибен һәм материалларын төзи;

- комиссия утырышына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия утырышы көн тәртибен раслау өчен комиссия рәисенә җибәрә;

- комиссия утырышына кадәр ике эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия әгъзаларына һәм кызыксынган затларга чираттагы комиссия утырышы көн тәртибе һәм материаллары белән таныштыра;

- утырыш башланырга бер эш көненнән дә соңга калмыйча комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

- комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

- комиссия утырышы йомгаклары буенча өч эш көне эчендә беркетмә әзерли һәм аны комиссия утырышында рәислек итүчегә имзалау өчен тапшыра;

- комиссия утырышын уздырган көннән алып ун эш көне эчендә комиссия карарларын материаллар тарату юлы белән комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга җиткерә;

- комиссия карарының күчермәсен кабул ителгән карарны үтәү өчен Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы оешмаларга, Баулы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына һәм башка оешмаларга җибәрә;

3.6. Комиссия әгъзалары:

- комиссия утырышларында катнашалар;

- карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм киңәшләр проектларын әзерлиләр;

- комиссия эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертәләр;

3.7. Комиссия утырышлары айга ике тапкыр уздырыла.

3.8. Комиссия утырышы, анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

3.9. Утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының яртысыннан артыграгы комиссия карары өчен тавыш бирсә, комиссия карары кабул ителгән дип санала. Җәлеп ителә торган белгечләр һәм экспертлар тавыш бирү хокукына ия түгел. Комиссия карарларын кабул иткәндә, комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булган очракта, комиссия рәисе (утырышта рәислек итүче комиссия рәисе урынбасары) хәлиткеч тавыш хокукына ия.

3.10. Комиссия утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларны комиссия рәисе имзалый. Комиссия рәисе булмаган очракта беркетмәне комиссия рәисе урынбасарларының берсе имзалый.

3.11. Комиссия эшчәнлеген оештыру, техник яктан тәэмин итү Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр оештыру бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.